ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 июнь 2022 ел № 3192

Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4418 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муницииаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәнең 61 пунктына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 февралендәге 187 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4418 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муницииаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы – гариза бирелгән көннән башлап 45 календарь көн.»

2) 2.8.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктча өстәргә:

«8) бакча йортын су басу, су керү зонасы чикләрендә урнашкан җир участогында урнаштыру (бакча йортын торак йорт дип тану турында гаризаны караганда).».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы

рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов